**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР №39**

**Урыссу ш.т.п.** **«_24__» декабрь 2018 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 03 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018елның 06 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 10 ноябрендәге 15 номерлы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 бүлекнең 1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «шәхси яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; съездда (конференция) яки бүтән иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, бакчачылык, яшелчә бакчасы, дачаның гомуми җыелышында катнашудан, кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләре; муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән әлеге коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә катнашудан тыш, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булып торган муниципаль берәмлек, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) оештыру яисә идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез рәвештә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очракларда».

1.2. 28.1 статьяның 2 пунктын «Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җәза куллану турында белешмәләр» абзацында муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.

1.3. Нигезләмәнең 28.1 статьясындагы 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча докладына, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы аның ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге хокук бозулардан тыш)».

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы-
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.М.Нуриев